**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№10343**
**27.10.2023**

Башкарма комитетның «Мәгълүмати элмә такта урнаштыру, элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 декабрендәге 8502 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә карата таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Мәгълүмати элмә такта урнаштыру, элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 декабрендәге 8502 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) административ регламентта:

- 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе»;

- 3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан запросның электрон формасының һәр кырын тутыру процессында, Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал запросның электрон формасының дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, турыдан-туры запросның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

- 3.5.2 пунктның алтынчы абзацында «ике эш көне эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.5.3 пунктта:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын (алга таба

– документлар проектлары) килештерү һәм имзалау муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы бүлек башлыгы, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

б) бишенче абзацта «ике эш көне эчендә» сүзләрен «өч эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

- административ регламентка 3 нче кушымтаны кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 27 октябрендәге
10343 номерлы карарына
кушымта

Мәгълүмати элмә такта урнаштыру, элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Юридик затлар өчен

(җирле үзидарә органының исеме)

______________________________

______________________________
(оешманың тулы исеме һәм оештыру-хокукый формасы)

______________________________
исеменнән
(җитәкченең яки башка вәкаләтле затның Ф.И.А.и.)
Гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ:
______________________________
(документ төре)
______________________________
(серия, номер)
______________________________
(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)
Юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар:
ОГРН
______________________________
______________________________
ИНН
______________________________
Урнашу урыны
______________________________
______________________________
Элемтә мәгълүматы:
тел.номеры 1 ______________________
тел.номеры 2 ______________________
эл. почта ________________________

Шәхси эшмәкәрләр өчен

Ф.И.А.и.

________________________________________

Шәхесне раслаучы документ:

________________________________________

(документ төре)

________________________________________

(серия, номер)

________________________________________

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

ОРГНИП (ШЭ өчен)

________________________________________

Теркәлү адресы

________________________________________

________________________________________

Ышаныч язуы буенча вәкил яки законлы вәкил:

Ф.И.А.и.

________________________________________

Шәхесне раслаучы документ:

________________________________________

(документ төре)

________________________________________

(серия, номер)

________________________________________

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Вәкаләтләрне раслаучы документ реквизитлары:

________________________________________

Теркәлү адресы

________________________________________

________________________________________

Элемтә мәгълүматы:

тел.номеры 1 ____________________________

тел.номеры 2 ____________________________

эл. почта ________________________________

Гариза

________________________________________________________________________

адресы буенча элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерүне сорыйм.

Гариза бирүче тарафыннан биләнә торган бинаның яисә мәгълүмати элмә такта беркетелә торган җир участогының кадастр номеры _____________________________________.

Өстәмә мәгълүмат: ______________________________________________________________.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1) ______________________________________________________________
2) ______________________________________________________________
3) ______________________________________________________________
4) ______________________________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирүне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

☐ Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәгендә.

☐ Башкарма комитетта.

_______________ | __________________ ( _________________)
(дата) | (имза) | (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева